1

**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

23.11.2022 1109-п

«Татарстан Республикасының Геология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану буенча фәнни-җитештерү берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесенә Татарстан Республикасы бюджетыннан башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.1 статьясындагы 1 пункты, бюджет һәм автоном учреждениеләргә башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен билгели торган, норматив хокукый актларга һәм муниципаль хокукый актларга карата Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 22 февралендәге 203 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының бюджет һәм автоном учреждениеләренә башка максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен билгеләргә вәкаләтле булган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларын көчен югалткан дип тану турында» 2022 елның 28 февралендәге 178 номерлы карары белән билгеләнгән гомуми таләпләр нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы аңа карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкара торган «Татарстан Республикасының Геология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану буенча фәнни-җитештерү берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесенә Татарстан Республикасы бюджетыннан башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен (кушымтада бирелә) расларга.

2. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары Е.А. Тарнавскийга йөкләргә.

Министр А.В. Шадриков

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать
ресурслар министрлыгының
23.11.2022 ел, №1109-п боерыгы
белән расланды

**«Татарстан Республикасының Геология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану буенча фәнни-җитештерү берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесенә Татарстан Республикасы бюджетыннан башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибе**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы (алга таба – Министрлык) аңа карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкара торган «Татарстан Республикасының Геология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану буенча фәнни-җитештерү берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесенә (алга таба – Учреждение) башка максатларга, дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанс яктан тәэмин итүгә бәйле булмаган максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгели.

2. Субсидияләр бер тапкыр бирелә һәм Учреждениегә дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанс яктан тәэмин итүгә кагылмый торган чараларны гамәлгә ашыру максатларында бирелә, шул исәптән:

күчемсез мөлкәт объекты булмаган төп чараларны сатып алуга;

Учреждениенең төп эшчәнлеген алып бару белән бәйле башка чараларны гамәлгә ашыруга;

3. Дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанс яктан тәэмин итүгә карамый торган чараларны гамәлгә ашыру өчен субсидияләр республика законнары һәм (яки) Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә бюджет ассигнованиеләре һәм Министрлыкка расланган бюджет йөкләмәләре чикләрендә Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет исемлеге нигезендә бирелә.

4. Финанс елына субсидияләр исемлеге әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта нигезендә форма буенча Министрлык боерыгы белән раслана.

## II. Башка максатларга субсидияләр бирү шартлары һәм тәртибе

5. Субсидияләр Учреждениенең салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнарны, җыемнарны, иминият кертемнәрен, пеняларны, штрафларны, процентларны түләүдә үтәлмәгән

йөкләмәләре, Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләрне кайтарып бирү буенча түләнмичә калган бурычлары булмаган очракта бирелә.

6. Субсидияне алу өчен, Учреждение Министрлыкка түбәндәге документларны (алга таба –гариза) җибәрә:

гариза бирелә торган айдан алда килгән айның 1 нче көненә булган торышында Учреждениенең салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнарны, җыемнарны, иминият кертемнәрен, пеняларны, штрафларны, процентларны түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләренең булмавын раслый торган салым органы белешмәсе;

гариза бирелгән айдан алда килгән айның 1 нче көненә булган торышында Учреждениенең башка норматив хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләрне Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарып бирү буенча түләү вакыты узган бурычларының булмавы турында Учреждение мөһере белән беркетелгән белешмә;

әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән субсидияләрне алуга 1, 2 форма (2 нче кушымта) буенча гариза;

субсидия бирү кирәклеген нигезләгән аңлатма язуы;

чыгымнарның беренчел сметасын теркәп, субсидия күләмен исәпләү-нигезләү;

субсидия бирү максатына бәйле рәвештә, нигезли торган башка документлар.

7. Әлеге Тәртипнең 6 пунктындагы өченче-җиденче абзацларында күрсәтелгән, субсидия алу өчен документлар учреждение җитәкчесе һәм учреждениенең баш бухгалтеры тарафыннан имзалана.

8. Субсидия бирү өчен документлар Министрлык тарафыннан субсидия бирелә торган елга кадәрге елның 1 октябренә кадәрге срокта (кәгазь чыганакта) кабул ителә.

9. Әлеге Тәртипнең 6 пунктында каралган документларны карау алар Министрлыкка алынган көннән башлап 20 эш көне эчендә Министрлыкның учреждение эшчәнлегенә кураторлык итүче структур бүлекчәсе тарафыннан гамәлгә ашырыла. Министрлык тарафыннан карарлар кабул итү өчен нигез булып торучы документларда мәгълүматларның дөреслеге һәм тулылыгы өчен җаваплылык Учреждениегә йөкләнә.

10. Документларны карау нәтиҗәләре буенча Министрлыкның учреждение эшчәнлегенә кураторлык итүче структур бүлекчәсе тарафыннан субсидия күләме һәм аны бирүнең нигезлелеге турында бәяләмә төзелә, ул Министрлыкның финанс контроле, исәпкә алу һәм хисап бүлегенә гаризаны һәм әлеге Тәртипнең 6 пунктында каралган документларны теркәп тапшырыла.

11. Учреждениегә субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

Учреждение тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 6 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве һәм (яки) әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

Учреждение тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы;

Учреждениенең әлеге Тәртипнең 6 пунктындагы икенче һәм өченче абзацларында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве.

12. Әлеге Тәртипнең 11 пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча субсидия бирүдән баш тарткан очракта, баш тарту өчен нигез булган кисәтүләрне баш тарту турында хат алынган көннән башлап биш эш көненнән кимрәк булмаган срокта бетерү шарты белән, Учреждение Министрлыкка әлеге Тәртипнең 6 пунктында каралган документларны кабат тапшырырга хокуклы. Кабат тапшырылган документларны карау әлеге Тәртипнең 9 пунктында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

13. Әлеге Тәртипнең 2 пунктында каралган субсидияләр күләме әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән документлар нигезендә билгеләнә һәм Учреждение гаризасында күрсәтелгән суммадан артып китә алмый.

14. Министрлык һәм учреждение арасында субсидияләр бирү максатларында билгеләнгән форма буенча килешү (3 нче кушымта) (алга таба – Килешү) төзелә, анда түбәндәге нигезләмәләр була:

субсидияне бирү максатлары;

субсидиянең күләме;

субсидияне күчерү вакыты (графигы);

хисаплылык тапшыру вакыты һәм формалары;

Учреждение Килешүдә билгеләнгән субсидия бирү максатларын, шартларын һәм тәртибен үтәмәгән очракта, субсидия суммаларын кире кайтару тәртибе һәм чорлары;

Килешүгә үзгәрешләр кертү нигезләре һәм тәртибе, шул исәптән Министрлыкка, әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга элегрәк бюджет акчаларын алучы буларак, бюджет йөкләмәләренең лимитларын киметкән очракта да;

Министрлык карары буенча берьяклы тәртиптә Килешүне вакытыннан алда туктату нигезләмәләре, шул исәптән Учреждениене үзгәртеп кору яки бетерүгә һәм Учреждение тарафыннан әлеге Тәртип һәм Килешү нигезендә билгеләнгән субсидия бирү максатларын һәм шартларын бозуга бәйле рәвештә дә;

Учреждение тарафыннан Килешүне берьяклы тәртиптә өзүгә бәйле рәвештә;

башка нигезләмәләр (кирәк булган очракта).

15. Министрлык һәм Учреждение арасындагы Килешү түбәндәге шартларны үтәгәндә төзелә:

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан субсидия бирү өчен бюджет йөкләмәләре лимитларын Министрлыкка җиткерү;

бер финанс елы өчен килешү төзү;

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан бюджет йөкләмәләре лимитларын Министрлыкка җиткергәннән соң 15 эш көне эчендә килешү төзү;

субсидия бирү турында килешү төзү планлаштырылган айга кадәр булган айның 1нче көненә Учреждениенең түбәндәге таләпләргә туры килүе: Учреждениенең салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычларының булмавы; субсидия бирү күздә тотылган Татарстан Республикасы бюджетына субсидияне кире кайтару буенча түләү вакыты узган бурычының булмавы

Килешү, шулай ук аңа үзгәрешләр кертү яки аны юкка чыгаруны күздә тоткан өстәмә килешүләр ике нөсхәдә кәгазьдә документ рәвешендә, якларның һәркайсы өчен берәр нөсхәдә төзелә.

16. Субсидия күчерү, субсидия бирү максатларыннан чыгып, Килешүдә билгеләнә торган субсидия күчерү графигы нигезендә, гамәлдәге Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә Учреждениегә керүче акчалар белән операцияләрне исәпкә алу өчен ачылган Учреждениенең шәхси счетына гамәлгә ашырыла.

## III. Хисаплылыкка карата таләпләр

17. Учреждение квартал саен, хисап аеннан соң килгән айның 10 нчы көненә кадәр, Министрлыкка финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнар турындагы хисапны, аңлатма язуын һәм түләүләрне раслаучы документларны тапшыра. Хисап формасы Килешүдә билгеләнә, шулай ук, Министрлык тарафыннан аны тапшыру турында карар кабул ителгән очракта, башка мәгълүмат.

## IV. Субсидияләрне бирү максатлары, шартлары һәм тәртибе үтәлешенә контрольлекне һәм аларны үтәмәгән өчен җаваплылыкны гамәлгә ашыру тәртибе

18. Агымдагы финанс елының 1 гыйнварына карата файдаланылмаган, Министрлык тарафыннан аңа ихтыяҗ булу турында карар кабул ителмәгән субсидиянең калган өлеше Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга (түләттерелергә) тиеш.

19. Агымдагы финанс елы башына файдаланылмый торган субсидия акчаларының калган өлешен субсидия биргәндә билгеләнгән максатларга ирешүгә юнәлтү ихтыяҗы булуы турында карар Министрлык тарафыннан Учреждениедән әлеге ихтыяҗны нигезли торган документлар алынган көннән соң 10 эш көне узганчы, ләкин агымдагы финанс елының 1 февраленнән дә соңга калмыйча кабул ителә.

20. Агымдагы финанс елы башына файдаланылмаган субсидия акчаларының калган өлеше, бу акчаларны субсидия биргәндә билгеләнгән максатларга юнәлтү ихтыяҗы турында Министрлык карары булмаган очракта, агымдагы финанс елында Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

21. Учреждениегә субсидия бирү максатлары һәм шартлары үтәлешен тикшереп тору Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә Министрлык һәм дәүләт финанс контроленең вәкаләтле органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

22. Министрлык һәм (яисә) дәүләт финанс контроленең вәкаләтле органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәсендә әлеге Тәртип һәм Килешү нигезендә билгеләнгән максатларны һәм шартларны бозу фактлары, шул исәптән субсидияне максатчан билгеләнештә файдаланмау фактлары ачыкланган очракта, акчалар Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш:

Министрлык таләбе нигезендә – Учреждение тарафыннан тиешле таләпләр алынганнан соң 10 эш көне эчендә;

дәүләт финанс контроленең вәкаләтле органы тәкъдиме һәм (яисә) күрсәтмәсе нигезендә – Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә билгеләнгән срокта.

23. Министрлык һәм (яисә) дәүләт финанс контроленең вәкаләтле органнары тарафыннан субсидияне бирү нәтиҗәләренә ирешү өчен кирәкле күрсәткечләргә ирешмәү фактлары (алар ачыкланган очракта) билгеләнгән очракта, Килешү Министрлык карары буенча бер яклы тәртиптә өзелә ала, ә Килешүне өзү көненә яисә хисап елыннан соңгы елның 1 нче гыйнварына (Килешүнең гамәлдә булу чоры беткәч) субсидия күләменең файдаланылмый калган өлеше күләмендәге акчалар әлеге Тәртипнең 22 пунктының икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарып бирелергә тиеш. Субсидия алучы әлеге акчаларны ирекле рәвештә кире кайтарып бирүдән баш тартканда, алар суд тәртибендә түләттерелә.

24. Учреждениене әлеге Тәртипнең 23 пунктында каралган җаваплылык чараларын кулланудан азат итү өчен нигез булып Учреждение тарафыннан тиешле йөкләмәләр үтәлешенә комачаулый торган, җиңеп булмаслык шартларның барлыкка килүе турында документаль раслама тора.

25. Бу Тәртип һәм Килешү нигезендә каралган максатлар һәм шартлар буенча субсидияләрне куллану өчен Учреждение җаваплы була.

«Татарстан Республикасының
Геология һәм җир асты
байлыкларыннан файдалану

буенча фәнни-җитештерү
берләшмәсе» дәүләт бюджет
учреждениесенә Татарстан
Республикасы бюджетыннан
башка максатларга субсидияләр
бирү күләмен һәм шартларын
билгеләү тәртибенә
1 нче кушымта

__________ елга башка максатларга субсидияләр исемлеге

| т/с | Башка максатларга субсидия исеме | Башка максатларга аны гамәлгә ашыру өчен субсидия бирелә торган чара | Норматив хокукый акт | Суммасы |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |

«Татарстан Республикасының
Геология һәм җир асты
байлыкларыннан файдалану

буенча фәнни-житештерү
берләшмәсе» дәүләт бюджет
учреждениесенә Татарстан
Республикасы бюджетыннан
башка максатларга субсидияләр
бирү күләмен һәм шартларын
билгеләү тәртибенә
2 нче кушымта

(1 форма)

____ елга субсидия бирүгә
«ТР Геология үзәге фәнни-житештерү берләшмәсе» ДБУ тарафыннан
ГАРИЗА

1. Төп чаралар/җиһазлар исемлеге:

| т/с | Җайланманың/төп чараның исеме, маркасы, моделе | Бәясе, сум | Бәясен нигезләү | Саны, данә | Барлыгы, сум. |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |

2. Учреждениенең җиһазланышын һәм җиһазларның/төп чараның искерү срогын исәпкә алып, җайланма/төп чара сатып алу кирәклеген нигезләү (аңлатма язуы)

Җитәкче _____________Ф.И.А.
(имза)
м. у.

Баш бухгалтер __________Ф.И.А.
(имза)

(2 форма)

____ елга субсидия бирүгә

«ТР Геология үзәге фәнни-житештерү берләшмәсе» ДБУ тарафыннан
ГАРИЗА

1. Күрсәтелә торган (хезмәтләр) эшләр исемлеге:

| Тәртип саны | Чараның атамасы | Бәясе, сум | Бәясен нигезләү | Саны, берәмлек. | Барлыгы, сум. |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |

2. Чараларны үткәрү кирәклеген нигезләү (аңлатма язуы)

Житәкче _____________Ф.И.А.
(имза)
м. у.

Баш бухгалтер __________Ф.И.А.
(имза)

«Татарстан Республикасының
Геология һәм җир асты
байлыкларыннан файдалану буенча

фәнни-җитештерү берләшмәсе»
дәүләт бюджет учреждениесенә
Татарстан Республикасы
бюджетыннан башка максатларга
субсидияләр бирү күләмен һәм
шартларын билгеләү тәртибенә
3 нче кушымта

**«Татарстан Республикасы Геология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану фәнни-җитештерү берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесенә Татарстан Республикасы бюджетыннан башка максатларга субсидия бирү турында килешү**

Казан шәһәре
«___» __________ 20__ел.
№__

**Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы,** алга таба «Гамәлгә куючы» дип атала, ____________________ йөзендә, ______________________ нигезендә эш итә, бер яктан, һәм **«Татарстан Республикасы Геология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану фәнни-җитештерү берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесе**, алга таба «Учреждение» дип атала, ______________________ йөзендә, Устав нигезендә эш итә, икенче яктан, алга таба «Яклар» дип аталып, Россия Федерациясенең Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасының _________ ел, № ____ күрсәтмәсе нигезендә түбәндәгеләр турында әлеге Килешүне төзеделәр.

I. Килешү предметы

1.1. Әлеге Килешүнең предметы булып Учреждениегә Татарстан Республикасы бюджетыннан ____ елда башка максатларга субсидияләр бирү тора, ______________

II. Субсидия бирү тәртибе, шартлары һәм дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанс белән тәэмин итү

2.1. Субсидия Учреждениегә түбәндәге максатларда бирелә, _______________.

2.2. Субсидия Гамәлгә куючыга Россия Федерациясе бюджетлары чыгымнарын классификацияләү кодлары (алга таба – БК кодлары) буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын алучы буларак җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә:

БК коды буенча 701.0404.0930192990.201 – __________ (_______) сум 00 тиен.

Барлыгы: _____________ (_____________) сум 00 тиен.

2.3. Килешүнең 1.1 пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын алучы буларак Гамәлгә куючыга бирелгән бюджет йөкләмәләренең лимитлары кимегәндә бирелә торган Субсидия күләме киметелергә мөмкин.

## III. Субсидияне күчерү тәртибе

3.1. Субсидия әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булган Субсидия күчерү графигы нигезендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган Учреждениенең шәхси счетына билгеләнгән тәртиптә күчерелә.

## IV. Якларның бәйләнышлары

4.1. Гамәлгә куючы бурычлы:

4.1.1. Әлеге Килешүнең 1.1 пунктында күрсәтелгән максатка (максатларга) Субсидия бирүне тәэмин итәргә;

4.1.2. Субсидия күчерү турында карар кабул итү максатларында Учреждение тарафыннан Гамәлгә куючыга җибәрелә торган документларны аларда күрсәтелгән касса чыгымнарының әлеге Килешүнең 1.1 пунктында күрсәтелгән Субсидия бирү максатына (максатларына) туры килү-килмәве предметы буенча документлар Учреждениедән алынган көннән соң 10 эш көне эчендә тикшерергә;

4.1.3. Әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булып торган бу Килешүнең 2 нче кушымтасы нигезендә әлеге Килешүнең VII бүлегендә күрсәтелгән Учреждение счетына Субсидия күчерелүен тәэмин итәргә;

4.1.4. Дәүләт учреждениесенә бер елга бирелгән максатчан субсидияләр белән операцияләр турындагы белешмәләр (ф. 0501016) формасы буенча бер елга Учреждениегә бирелгән максатчан субсидияләр белән операцияләр турындагы белешмәләрне (алга таба – Белешмәләр), кертелгән үзгәрешләре исәпкә алынган Белешмәләрне әлеге документлар Учреждениедән әлеге Килешүнең 4.3.2 пункты нигезендә алынган көннән соң 10 эш көне узганчы расларга;

4.1.5. Учреждение тарафыннан Субсидия бирү тәртибендә һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән Субсидия бирү максатының (максатларының) һәм шартларының үтәлешен тикшереп торырга, түбәндәге чараларны гамәлгә ашыру юлы белән:

4.1.5.1. Планлы һәм плannan тыш тикшерүләр үткәрү:

4.1.5.1.1. Гамәлгә куючы урнашкан урын буенча, аның таләбе буенча әлеге Килешүнең 4.3.4 пункты нигезендә Учреждение тарафыннан тапшырылган документлар нигезендә;

4.1.5.1.2. Учреждение урнашкан урын буенча, Учреждение тарафыннан Субсидия акчаларын кулланып башкарылган операцияләрне документаль һәм фактик өйрәнү нигезендә;

4.1.5.2. Әлеге Килешүнең 4.1.5.1 пунктында күрсәтелгән тикшерү(ләр) нәтиҗәсендә Субсидияләрне бирү тәртибендә һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән максатны (максатларны) һәм шартларны бозу фактлары ачыкланган очракта (дәүләт финанс контроле органыннан Учреждение тарафыннан Субсидияләрне бирү

тәртибендә һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән максатны (максатларны) һәм шартларны бозу турында мәгълүмат алынганда), әлеге бозуларны бетергәнчегә кадәр, туктатып тору турында карар кабул иткәннән соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча Учреждениенә зарури тәртиптә белдереп, Субсидия бирүне туктатып торырга;

4.1.5.3. Әлеге Килешүнең 4.1.5.2 пунктында күрсәтелгән бозуларны бетермәгән очракны да исәпкә алып, Учреждениегә әлеге таләптә билгеләнгән күләмдә һәм срокларда Субсидияне яисә аның бер өлешен Гамәлгә куючыга Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарып бирү турында таләп җибәрергә;

4.1.6. Учреждение тарафыннан, шул исәптән әлеге Килешүнең 4.4.1-4.4.2 пунктларын нигезендә, җибәрелгән тәкъдимнәрне, документларны һәм башка мәгълүматны аларны алган көннән соң  эш көне эчендә карарга һәм кабул ителгән карар турында (кирәк булган очракта) Учреждениегә хәбәр итәргә;

4.1.7. Учреждениегә әлеге Килешүне үтәүгә бәйле мәсьәләләр буенча аңлатмаларны әлеге Килешүнең 4.4.5 пункты нигезендә Учреждениедән мөрәҗәгать алынган көннән алып 10 эш көне узганчы җибәрергә;

4.1.8. Россия Федерациясенең бюджет законнарында, Субсидия бирү кагыйдәләрендә һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән башка бурычларны башкарырга.

4.2. Гамәлгә куючы хаклы:

4.2.1. Әлеге Килешүнең 4.1.5 пункты нигезендә Субсидияләрне бирү тәртибендә һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән Субсидияне бирү максатын (максатларын) һәм шартларын Учреждение тарафыннан үтәүгә карата контрольлек башкару өчен кирәкле мәгълүматны һәм документларны Учреждениедән соратып алырга;

4.2.2. Әлеге Килешү шартларын үзгәртү турында, шул исәптән әлеге Килешүнең 4.4.2 пункты нигезендә Учреждение тарафыннан җибәрелгән мәгълүматлар һәм тәкъдимнәр нигезендә карар кабул итәргә, Субсидия күләмен киметүне дә кертеп, шулай ук әлеге Килешүнең 2.2 пунктында күрсәтелгән файдаланмаган бюджет йөкләмәләре лимитлары булганда һәм әлеге үзгәрешкә Учреждениедән финанс-икътисадый нигезләүне үз эченә ала торган мәгълүмат тапшырылу шарты белән, Субсидия күләмен арттырырга;

4.2.3. Учреждениедән Субсидиянең калган өлешен әлеге Килешүнең 1.1 пунктында күрсәтелгән максатка (максатларга) юнәлдерү зарурлыгын нигезли торган документлар алынганнан соң 30 эш көненнән соңга калмыйча, Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә бер ел эчендә кулланылмаган Субсидия өлеше калган елда аны, шулай ук Субсидияне кулланудан алдагы елларда барлыкка килгән дебиторлык бурычын кире кайтарудан Учреждениегә ____ елда килгән акчаларны әлеге Килешүнең 1.1 пунктында күрсәтелгән максатка (максатларга) юнәлдерү ихтыяҗының булуы яки булмавы турында карар кабул итәргә;

4.2.4. Россия Федерациясенең бюджет законнарында, Субсидияләрне бирү тәртибендә һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән башка хокукларны гамәлгә ашырырга.

4.3. Учреждение бурычлы:

4.3.1. Гамәлгә куючыга раслау өчен түбәндәгеләрне җибәрергә:

4.3.1.1. Әлеге Килешү төзелгән датадан соңгы 10 эш көненнән соңга калмыйча

белешмәләр;

4.3.1.2. Гамәлгә куючыдан Субсидия күләмен үзгәртү турында кабул ителгән карар турында мәгълүмат алынган көннән соң 10 эш көне узганчы, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып, белешмәләр;

4.3.2. Субсидияләрне бирү тәртибендә һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән Субсидия бирү шартлары нигезендә Субсидияне әлеге Килешүнең 1.1 пунктында күрсәтелгән максатка ирешү өчен Белешмәләрдә күрсәтелгән түләүләрне гамәлгә ашыру өчен тотарга;

4.3.3. Гамәлгә куючы гарызнамәсе буенча күрсәтелгән гарызнамәне алган көннән башлап 10 эш көненнән соңга калмыйча, әлеге Килешүнең 4.2.1 пункты нигезендә Субсидия бирү тәртибен, максатын (максатларын) һәм шартларын саклауга контрольне гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматны җибәрергә;

4.3.4. Субсидия алынган хисап кварталыннан (айдан, кварталдан, елдан) соң килә торган айның 10 нчы көненә кадәрге срокта Гамәлгә куючыга түбәндәгеләрне җибәрергә:

4.3.4.1. Финанс яктан тәэмин итү чыганагы булып Субсидия торган чыгымнар турында әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булып торган, әлеге Килешүгә 3 нче кушымта нигезендәге форма буенча хисап;

4.3.4.2. Гамәлгә куючыга бирелә торган башка хисаплар;

4.3.5. Гамәлгә куючы тарафыннан уздырылган тикшерү нәтиҗәләре буенча (дәүләт финанс контроле органыннан Учреждение тарафыннан Субсидияләрне бирү тәртибендә һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән Субсидияне бирү максатын (максатларын) һәм шартларын бозу турында мәгълүмат алынганнан соң), Субсидияне яки аның бер өлешен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарып бирүне дә кертеп, бозуны бетерү турында Гамәлгә куючыдан таләп алынган көннән башлап 10 эш көне эчендә Субсидияләрне бирү тәртибендә һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән Субсидия бирү максатын (максатларын) һәм шартларын бозуның ачыкланган очракларын бетерергә;

4.3.6. Агымдагы финанс елы ахырына файдаланылмаган Субсидиянең калган өлешен билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына күчерү юлы белән кире кайтарырга;

4.3.7. Россия Федерациясенең бюджет законнарында, Субсидияләрне бирү тәртибендә һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән башка бурычларны башкарырга.

4.4. Учреждение хаклы:

4.4.1. Хисап бирә торган финанс елыннан соң килгән 10 эш көненнән соңга калмыйча, әлеге Килешүнең 4.2.3 пунктында күрсәтелгән документларны Гамәлгә куючыга җибәрергә;

4.4.2. Әлеге Килешүгә үзгәрешләр кертү турында Гамәлгә куючыга тәкъдимнәр җибәрергә, шул исәптән Субсидиянең күләмен үзгәртү зарурлыгы билгеләнгән очракта да, әлеге үзгәрешкә финанс-икътисадый нигезләүне үз эченә ала торган мәгълүматларны теркәп;

4.4.3. Әлеге Килешү нигезендә бу Килешүнең 1.1 пунктында күрсәтелгән максат нигезендә түләүләрне гамәлгә ашыру өчен алынган Субсидиянең ел дәвамында кулланылмаган өлешен Гамәлгә куючының әлеге Килешүнең 4.2.3

пунктында күрсәтелгән карары нигезендә җибәрергә;

4.4.4. Әлеге Килешүнең 1.1 пунктында күрсәтелгән максат нигезендә түләүләрне гамәлгә ашыру өчен Субсидияне кулланудан барлыкка килгән алдагы елларның дебиторлык бурычын кире кайтарудан Учреждениегә ел дәвамында килгән акчаларны Гамәлгә куючының әлеге Килешүнең 4.2.3 пунктында күрсәтелгән карары нигезендә юлларга;

4.4.5. бу Килешүне үтәүгә бәйле рәвештә аңлатмаларны алу максатында Гамәлгә куючыга мөрәҗәгать итәргә;

4.4.6. Россия Федерациясенең бюджет законнарында, Субсидияләрне бирү тәртибендә һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән башка хокукларны гамәлгә ашырырга.

## V. Якларның җаваплылыгы

5.1. Бу Килешү нигезендә үзләренең бурычларын үтәмәү яисә тиешле дәрәҗәдә үтәмәү очрагында Яклар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы була.

## VI. Ахыргы нигезләмәләр

6.1. Гамәлгә куючы тарафыннан әлеге Килешүне берьяклы тәртиптә өзү түбәндәге очракларда мөмкин:

6.1.1. Үзгәртеп кору яки бетерү вакытында Учреждение эшчәнлеге туктатылган очракта;

6.1.2. Учреждение тарафыннан Башка максатларга субсидияләр бирү кагыйдәләрендә һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән субсидия бирү максатлары һәм шартлары бозылган очракта.

6.2. Килешүне өзү яклар килешүе буенча гамәлгә ашырыла һәм, әлеге Килешүнең 6.1 пунктында каралган берьяклы тәртиптә өзелүдән тыш, әлеге Килешүне өзү турында килешү рәвешендә рәсмиләштерелә.

6.3. Яклар арасында әлеге Килешүне үтәүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган бәхәсләр алар тарафыннан, мөмкин булганча, тиешле беркетмәләрне яки башка документларны рәсмиләштереп, сөйләшүләр үткәрү юлы белән хәл ителә. Килешүгә ирешелмәгән очракта, Яклар арасындагы бәхәсләр суд тәртибендә хәл ителә.

6.4. Әлеге Килешү имзаланган көннән башлап якларның һәркайсы исеменнән гамәлдә булу хокукына ия затлар тарафыннан үз көченә керә, ләкин әлеге Килешүнең 2.2 пунктында күрсәтелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары җиткерелгәннән дә иртәрәк түгел, һәм яклар тарафыннан әлеге Килешү буенча үз йөкләмәләрен тулысынча үтәгәнчегә кадәр гамәлдә була.

6.5. Әлеге Килешүне үзгәртү, шул исәптән әлеге Килешүнең 4.2.2 пункты нигезләмәләре нигезендә дә, яклар килешүе буенча гамәлгә ашырыла һәм әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булып торган өстәмә килешү рәвешендә рәсмиләштерелә.

6.6. Әлеге Килешүдә каралган документлар һәм башка мәгълүмат яклар тарафыннан түбәндәге ысул(лар) белән җибәрелергә мөмкин:

6.6.1. Татарстан Республикасы Электрон документлар әйләнеше мәгълүмат

системасын куллану юлы белән;

6.6.2. Документларның төп нөсхәләрен, башка мәгълүматны юллау турында икенче як вәкиленә теркәү хаты белән.

6.7. Әлеге Килешү яклар тарафыннан кәгазь документ рәвешендә ике нөсхәдә, якларның һәркайсысы өчен берәр нөсхәдә төзелде.

## VII. Якларның түләү реквизитлары

| | |
|---|---|
| Гамәлгә куючының исеме<br>Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы<br>ОГРН 1021603473616, ОКТМО 92701000 | Учреждениенең исеме<br>«Татарстан Республикасы Геология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану буенча фәнни-җитештерү берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесе ОГРН 1211600018640, ОКТМО 92701000 |
| Урнашу урыны:<br><br>420049, ТР, Казан ш.,<br>Павлюхин ур., 75. | Урнашу урыны:<br><br>420061, Казан ш.,<br>Космонавтлар ур., 59 йорт,<br>5 бүлмә. |
| ИНН/КПП 1659036508/165901001 | ИНН/КПП 1660360139/166001001 |
| Түләү реквизитлары:<br>Татарстан Республикасы буенча ФКИ (ТР ФМ ш/с 02112001110) Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы (ТР Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы, ЛБ007010001-АппМЭиПР)<br>исәп счеты<br>03221643920000001100<br>РОССИЯ БАНКЫНЫҢ ТР МИЛЛИ БАНКЫ БҮЛЕКЧӘСЕ//Татарстан | Түләү реквизитлары:<br>Татарстан Республикасы буенча ФКИ (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы ( "ТР Геология үзәге ФЖБ» БДУ LBG00701001- Геоүзәк))<br>исәп счеты<br>03224643920000001100<br>РОССИЯ БАНКЫНЫҢ ТР МИЛЛИ БАНКЫ БҮЛЕКЧӘСЕ//Татарстан Республикасы буенча ФКИ Казан шәһәре |

| | |
|---|---|
| Республикасы буенча ФКИ Казан шәһәре<br>БИК 019205400<br>к/с 40102810445370000079 | БИК 019205400<br>к/с 40102810445370000079 |

VIII. Якларның имзалары

| Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы | «ТР Геология үзәге ФҖБ» ДБУ |
|---|---|
| ___________ ________________<br>(имза) (ФИА) | ___________ ________________<br>(имза) (ФИА) |